**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 сентябрь № 678

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне өстәмә һөнәри укытуга дәүләт заказы турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1030 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне өстәмә һөнәри укытуга дәүләт заказы турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1030 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен өстәмә һөнәри укытуга дәүләт заказы структурасына искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмә: 2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен өстәмә һөнәри укытуга дәүләт заказын финанслау күләмен исәпләгәндә өстәмә дәүләт хезмәткәрләрен укыту мөмкинлеге күздә тотылган. Өстәмә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуга финанслау күләме 1 344 мең сумнан артык була алмый.»;

әлеге карар белән расланган 2016 елга Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләрен өстәмә һөнәри укытуга дәүләт заказы структурасына искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмә: 2016 елга Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләрен өстәмә һөнәри укытуга дәүләт заказын финанслау күләмен исәпләгәндә өстәмә

муниципаль хезмәткәрләрне укыту мөмкинлеге күздә тотылган. Өстәмә Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләрен укытуга финанслау күләме 1 344 мең сумнан артык була алмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\678.docx